**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь 2022 ел** **№ 8**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 21 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Чәбия авылы, Бакча урамы, 55 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчет йорты бинасы ишек алдында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Яңа Чәбия авылында урнашкан чишмәне төзекләндерү (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Елга аша басма кую (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- БТИ хезмәтләре өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»»?

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов